# ӘЙТМӘ СИН АВЫР СҮЗ

Рамиль Чурагулов сүзләре    Ризван Хәким музыкасы






## ӘЙТМӘ СИН АВЫР СҮЗ

1. Беркайчан әйтмә син авыр сүз,
Бик кыска, әй кыска гомерләр.
Син минем гомерлек юлдашым
Син чәчкәм, йолдызым сөйгән яр.

*Кушымта:* Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы
Гөрләтеп яшисе бар әле.

2. Бик авыр минутлар булса да
Тап миңа шул вакыт җылы сүз.
Авыр сүз әйтәсең килсә дә
Әйтмә син сөеклем, әйтмә түз.

*Кушымта:* Әйтмә син, әйтмә син, әйтмә түз,
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы
Гөрләтеп яшисе бар әле.

3. Иртәсен, кичен дә миңа син
Кызганма карашның җылысын.
Шул чакта сөюнең артуын
Йөрәгең белән син тоярсың.

*Кушымта:* Әйтмә син авыр сүз әйтмә син,
Йөрәк бит болай да яралы.
Җырларны шаулатып җырлыйсы,
Гөрләтеп яшисе бар әле.